| | |
|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕКЛЮЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | с.Большие | КАРАР |
| «09» декабря 2025 года | Ключи | № 194 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Олы Ключино авыл җирлеге Советы карар чыгарды::

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Ключино авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Ел саен Олы Ключи авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 13.03.2024 ел, № 160 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Олы Ключи авылы, Волостнов ур., 16А йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Ключи авылы, Волостнов ур., 21 йорт (кибет бинасы).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык урынбасары
Совет Рәисе — З. Р. Гатауллин